КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 14 июль г.Казань № 569

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны хисаплап чыгару тәртибен һәм Дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасын раслау турында» 2013 ел, 1 июнь, 376 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны хисаплап чыгару тәртибен һәм Дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасын раслау турында» 2013 ел, 1 июнь, 376 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 17 июль, 500 нче; 2018 ел, 14 август, 666 нчы; 2021 ел, 2 март, 109 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла һәм күрсәтелә торган дәүләт эшләренә һәм хезмәтләренә сарыф ителгән эш вакыты белән башкарылган эш күләме нормативларын Методика нигезендә раслауны һәм яңадан карауны

тәэмин итәргә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карар дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны хисаплап чыгаруның башка тәртипләре расланмаган Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләренә кагыла;

бухгалтерлык исәбе, физик затларга түләүләрне исәпләү, регламентланган хисаплылыкны формалаштыру һәм тапшыру эшләрен башкаручы хезмәткәрләр (бухгалтерлар) санының нормативы, 2022 елдан башлап, өч елга бер тапкыр Методика нигезендә билгеләнә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартын раслау турында» 2008 ел, 7 апрель, 207 нче карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының штат расписаниесен раслау максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары хезмәткәрләре санын бәяләү өчен Методиканы куллану рөхсәт ителә.»;

әлеге карар белән расланган Дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасында:

2 нче таблицаның «Бухгалтерлык исәбе» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «Бухгалтерлык исәбе, физик затларга түләүләрне исәпләү, регламентланган хисаплылыкны формалаштыру һәм тапшыру | хезмәткәрләр саны | штат расписаниесе нигезендә 300 штат берәмлегеннән торган физик затларга түләүләрне исәпләүләрне хисаплап чыгару буенча 1 белгеч ставкасы | + | |
| | | учреждение тарафыннан түләүләр түләнә торган башка 1 000 физик заттан торган физик затларга түләүләрне исәпләүләрне хисаплап чыгару буенча 1 белгеч ставкасы | + | |
| | | бухгалтерлык исәбе, регламентланган хисаплылыкны формалаштыру һәм тапшыру эшен башкаручы белгечнең өч елга билгеләп куела торган һәм бу Методиканың 4.2 пункты нигезендә билгеләнә торган ставкасы | +»; | |

түбәндәге эчтәлекле 4.2 һәм 4.3 пунктлар өстәргә:

«4.2. Бухгалтерлык исәбе, регламентланган хисаплылыкны формалаштыру һәм тапшыру эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив саны ($N_{bu}$) түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$N_{bu} = \frac{TR_{ot}}{8 \times 60 \times 240{,}5},$$

монда:

$TR_{ot}$ – эшләр башкару өчен сарыф ителгән эш вакыты белән башкарылган эшнең гомуми күләме;

8 – 1 көнгә эш сәгатьләре саны;

60 – 1 сәгатьтә минутлар саны;

240,5 – бер елда эш көннәре саны (биш көнлек эш атнасы булганда ял, бәйрәм көннәрен исәпкә алып).

Эшләр башкару өчен сарыф ителгән эш вакыты белән башкарылган эшнең гомуми күләме ($TR_{ot}$) түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$TR_{ot} = \left(\sum_{i=1}^{n} TR_{ot_i} \times Kp_i\right) \times 1,1,$$

монда:

$TR_{ot_i}$ – 3 нче таблица нигезендә эшнең i төре буенча сарыф ителгән эш вакыты белән башкарылган эш күләменең кабул ителә торган нормативы;

$Kp_i$ – бер елга эшләрнең ничә тапкыр кабатлануы;

1,1 – хезмәткәрләрнең һәм чит оешмаларның рәсми соравы буенча белешмә кәгазьләрен рәсмиләштерү эшен, шулай ук, төшке аш вакытын кертмичә, ял итүгә һәм шәхси кирәк-яракларга туктап тору вакытларын исәпкә ала торган төзәтү коэффициенты;

n – исәп-хисап алып барыла торган эшләр саны.

Түбәндәге тәртиптә түгәрәкләнә:

0,13 тән түбәнрәк йомгаклау саннары төшереп калдырыла,

0,13 тән 0,37 гә кадәр саннар 0,25 кә кадәр түгәрәкләнә;

0,38 дән 0,62 гә кадәр саннар – 0,5 кә кадәр;

0,63 тән 0,87 гә кадәр саннар – 0,75 кә кадәр,

0,87 дән югарырак – 1 гә кадәр.

3 нче таблица

Бухгалтерлык исәбе, регламентланган хисаплылыкны формалаштыру һәм тапшыру эшләрен башкаруга сарыф ителгән эш вакыты белән башкарылган эш күләмен билгеләү өчен кулланыла торган сарыф ителгән эш вакыты белән башкарылган эш күләме нормативлары

| Т/с | Эш төрләренең исеме | Эшләрнең эчтәлеге | Үлчәү берәмлеге | Сарыф ителгән эш вакыты белән башкарылган эш күләме нормативы, кеше сарыф иткән минут |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. Төп чараларны, матди булмаган һәм җитештерелмәгән активларны исәпкә алу | | | | |
| 1.1. | Инвентаризация үткәргәндә төп чараларның булуын исәпкә алу | Төп чараларның инвентаризация исемлегендә төп чараларның булуы турында мәгълүмат өземтәсе | инвентаризация исемлеге яки исәпкә алуның инвентарь карточкасы, 1 позиция | 2,4 |
| 1.2. | Инвентаризация үткәргәндә матди булмаган активларның булуын исәпкә алу | Матди булмаган активларның инвентаризация исемлегендә матди булмаган активларның булуы турында мәгълүмат өземтәсе | инвентаризация исемлеге яки исәпкә алуның инвентарь карточкасы, 1 позиция | 2,4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 1.3. | Инвентаризация үткәргәндә житештерелмәгән активларның булуын исәпкә алу | Җитештерелмәгән активларның инвентаризация исемлегендә җир кишәрлекләренең булуы турында мәгълүмат өземтәсе | инвентаризация исемлеге яки исәпкә алуның инвентарь карточкасы, 1 позиция | 2,4 |
| 1.4. | Төп чаралар хәрәкәтен исәпкә алу:<br>а) яңа төзелгән;<br>б) түләүсез алынган;<br>в) хуҗалык ысулы белән эшләнгән | Төп чаралар картотекасын алып бару һәм төп чаралар хәрәкәтен исәпкә алу буенча әйләнеш ведомостенда аларның хәрәкәтен исәпкә алу | исәпкә алу карточкасы, 1 позиция | 8,5 |
| | | Операцияләр журналында алынган нәтиҗәләрне анализлау | операцияләр журналы, 1 позиция | 20,0 |
| 1.5. | Матди булмаган активларның хәрәкәтен исәпкә алу:<br>а) кайтартучылардан сатып алынган;<br>б) түләүсез алынган;<br>в) үз көчләре белән ясалган;<br>г) модернизацияләү | Матди булмаган активлар картотекасын алып бару һәм матди булмаган активлар хәрәкәтен исәпкә алу буенча әйләнеш ведомостенда аларның хәрәкәтен исәпкә алу | исәпкә алу карточкасы, 1 позиция | 8,5 |
| | | Операцияләр журналында алынган нәтиҗәләрне анализлау | операцияләр журналы, 1 позиция | 20,0 |
| 1.6. | Төп чараларны исәпкә алу | Төп чараларны исәпкә алу операциясе чагылдырыла торган счетлар буенча һәр айның әйләнеш ведомостен формалаштыру | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 12,0 |
| 1.7. | Матди булмаган активларны исәпкә алу | Матди булмаган активларны исәпкә алу операциясе чагылдырыла торган счетлар буенча һәр айның әйләнеш ведомостен формалаштыру | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 12,0 |
| 1.8. | Җитештерелмәгән активларны исәпкә алу | Җитештерелмәгән активларны исәпкә алу операциясе ча- | әйләнеш ведомосте, | 12,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | гылдырыла торган счетлар буенча һәр айның әйләнеш ведомостен формалаштыру | 1 позиция | |
| 1.9. | Төп чараларны файдаланмый башлау һәм башка урынга күчерү операцияләрен исәпкә алу | Һәр документ буенча операцияләр журналында язу | операцияләр журналы, 1 позиция | 12,0 |
| 1.10. | Матди булмаган активларны файдаланмый башлау һәм башка урынга күчерү операцияләрен исәпкә алу | Һәр документ буенча операцияләр журналында язу | операцияләр журналы, 1 позиция | 12,0 |
| 1.11. | Җитештерелмәгән активларны файдаланмый башлау һәм башка урынга күчерү операцияләрен исәпкә алу | Һәр документ буенча операцияләр журналында язу | операцияләр журналы, 1 позиция | 12,0 |
| 1.12. | Төп чараларның исәпләнгән амортизациясен исәпкә алу | Операцияләр журналында исәпләнгән амортизация суммасын язу | операцияләр журналы, 1 позиция | 12,0 |
| 1.13. | Матди булмаган активларның исәпләнгән амортизациясен исәпкә алу | Операцияләр журналында исәпләнгән амортизация суммасын язу | операцияләр журналы, 1 позиция | 12,0 |
| 2. Матди запасларны исәпкә алу | | | | |
| 2.1. | Производстводан складка тапшырылган әзер әйберләрне һәм | Производстводан складка тапшырылган әзер әйберләр һәм продукция керүне чагылдыру. Матди кыйммәтләрне исәпкә алу карточкасын алып бару. Бухгалтерлык һәм | исәпкә алу карточкасы, 1 позиция | 16,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | продукцияне керемгә язуны исәпкә алу | склад исәбендәге мәгълүматны чагыштырып тикшерү | | |
| 2.2. | Ярдәмче хуҗалыкларның әзер әйберләрен һәм продукциясен реализацияләүне исәпкә алу | Ярдәмче хуҗалыкларның әзер әйберләрен һәм продукциясен кабул итү актлары яки башка документлар ярдәмендә керемгә язу. Тиешле формалардагы исәпкә алу карточкаларында исеме, саны, кыйммәте һәм саклау урыннары буенча аналитик исәпкә алу | исәпкә алу карточкасы, 1 позиция | 12,0 |
| 2.3. | Планлы һәм факттагы үзкыйммәт арасындагы аермага төзәтүләр кертүне исәпкә алу | Ел ахырында планлы үзкыйммәткә реализацияләнгән продукция суммасында факттагы үзкыйммәткә кадәр төзәтмәләр кертү. Планлы үзкыйммәтне экономияләүне хисаплап чыгару | исәпкә алу карточкасы, 1 позиция | 12,0 |
| 2.4. | Кайтартучыдан төзелеш өчен җиһаз һәм төзелеш материаллары алуны, симертү өчен терлек, материаллар һәм азык-төлек продуктлары, ягулык-майлау материаллары, дару препаратлары һәм медицина материаллары, товарлар һәм башка матди запаслар сатып алуны исәпкә алу | Матди запасларны исәпкә алу карточкаларында саны һәм кыйммәте буенча матди запасларны аналитик исәпкә алу | исәпкә алу карточкасы, 1 позиция | 4,5 |
| 2.5. | Матди запасларны исәптән чыгаруны исәпкә алу | Җиһаз, төзелеш материаллары, озак файдаланудагы материаллар, ягулык-майлау материалларын исәптән төшерү | исәпкә алу карточкасы, 1 позиция | 3,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Исәптән төшерү актлары яки башка документлар нигезендә материалларның һәм туклану продуктларының җитеп бетмәвен һәм югалуларын исәпкә алу | | |
| 2.6. | Туклану продуктларын исәпкә алу | Менюга калькуляция ясау, туклану продуктларын исәптән төшерү, туклану продуктлары чыгымыннан өземтә | меню-таләп, 1 позиция | 3,0 |
| 2.7. | Инвентаризация үткәргәндә матди запасларның булу-булмавын исәпкә алу | Инвентаризация исемлегендә матди запасларның булуы турында мәгълүмат өземтәсе | инвентаризация исемлеге яки исәпкә алу карточкасы, 1 позиция | 2,4 |
| | | 3. Йомшак инвентарьны исәпкә алу | | |
| 3.1. | Йомшак инвентарьны исәпкә алу | Матди кыйммәтләрне исәпкә алу карточкаларында яки материалларны склад исәбенә алу кенәгәсендә йомшак инвентарьны исәпкә алу. Бухгалтерлык һәм склад исәбендәге мәгълүматны чагыштырып тикшерү | исәпкә алу карточкасы, 1 позиция | 5 |
| 3.2. | Йомшак инвентарьны складтан эксплуатацияләүгә бирүне исәпкә алу | Йомшак инвентарьны складтан җибәрү өчен кирә торган документацияләрне эшкәртү | накладной, таләп-накладной, 1 позиция | 5 |
| | | Матди кыйммәтләрне исәпкә алу карточкасында һәм операцияләр журналында складтан бирүне исәпкә алу буенча бухгалтерлык операцияләрен чагылдыру. Бухгалтерлык һәм склад исәбендәге мәгълүматны чагыштырып тикшерү | операцияләр журналы, 1 позиция | 5 |
| 3.3. | Яраксыз хәлгә килгән йомшак инвентарьны исәптән төшерү | Йомшак инвентарьны исәптән төшерү өчен кирә торган документацияләрне эшкәртү. Җитәкчелек тарафыннан расланган йомшак һәм хуҗалык инвентарен исәптән төшерү акты нигезендә йомшак инвентарьны исәптән төшерү | йомшак һәм хуҗалык инвентарен исәптән төшерү акты, 1 позиция | 5 |
| 3.4. | Йомшак инвентарь хәрәкәтен исәпкә алу | Йомшак инвентарьны исәпкә алу операциясе чагылды- | операцияләр жур- | 3,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | рыла торган счетлар буенча һәр айның әйләнеш ведомостен формалаштыру Операцияләр журналында кирәкле хисаплылыкны алып бару | налы, әйләнеш ведомосте, 1 позиция | |
| 3.5. | Инвентаризация үткәргәндә йомшак инвентарьның булуын исәпкә алу | Инвентаризация исемлегендә йомшак инвентарьның булуы турында мәгълүмат өземтәсе | инвентаризация исемлеге яки исәпкә алу карточкасы, 1 позиция | 2,4 |
| 4. Җитештерү һәм башка максатлар чыгымнарын исәпкә алу | | | | |
| 4.1. | Продукция җитештерү буенча һәм фәнни тикшеренү һәм конструкторлык эшләрен башкару буенча турыдантуры чыгымнарны исәпкә алу | Фәнни тикшеренү һәм конструкторлык эшләре буенча аналитик исәпкә алу күп графалы карточкаларда чыгымнар темалары һәм статьялары буенча алып барыла | күп графалы карточкалар, 1 позиция | 16 |
| 4.2. | Хуҗалык шартнамәләре буенча продукция җитештерү һәм фәнни тикшеренү эшләрен башкару өчен складтан материаллар һәм махсус җиһаз бирүне исәпкә алу | Продукция җитештерү һәм фәнни тикшеренү эшләрен башкару өчен складтан материаллар һәм махсус җиһаз җибәрүгә документацияләрне теркәү. Матди кыйммәтләрне исәпкә алу карточкасында һәм операцияләр журналында материаллар җибәрүне чагылдыру. Бухгалтерлык һәм склад исәбендәге мәгълүматны чагыштырып тикшерү | операцияләр журналы, 1 позиция | 4,0 |
| 4.3. | Кайбер җитештерү төрләре һәм заказлар буенча өстәмә тотылган чыгымнар бүленешен исәпкә алу | Өстәмә тотылган чыгымнар суммасын хисаплап чыгару, операцияләр журналында өстәмә тотылган чыгымнарны исәпкә алу һәм бүлү буенча бухгалтерлык операцияләрен чагылдыру | операцияләр журналы, 1 позиция | 12,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 4.4. | Җитештерү остаханәләре һәм ашханәләре күрсәткән хезмәтләрне реализацияләүне исәпкә алу | Операцияләр журналында җитештерү остаханәләрендә һәм ашханәләрдә күрсәтелгән хезмәтләрне реализацияләүне исәпкә алу буенча бухгалтерлык операцияләрен чагылдыру | операцияләр журналы, 1 позиция | 4,2 |
| | | 5. Акчаны исәпкә алу | | |
| 5.1. | Түбәндәгеләрдәге шәхси счетларны исәпкә алу:<br>а) финанс органындагы;<br>б) коммерция банкларындагы (валюта счетлары) | Учреждениеләрнең шәхси счетларында финанслау чагылдырыла торган счетлар буенча һәр көннең әйләнеш ведомостьларын формалаштыру. Учреждениеләр счетларындагы ассигнованиеләрнең калган өлеше мәгълүматын банктагы шәхси счетлар мәгълүматлары белән чагыштырып тикшерү | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 3 |
| 5.2. | Касса чыгымнарын торгызуга акча хәрәкәтен исәпкә алу | Операцияләр журналында касса чыгымнарын торгызу өчен акча хәрәкәте чагылдырыла торган счетлар буенча әйләнешләрне формалаштыру | операцияләр журналы, 1 позиция | 4 |
| 5.3. | Яңа төзелешкә һәм хезмәтләр күрсәтүгә матди кыйммәтләр, җиһазлар, төзелеш материаллары өчен кайтартучыга түләү счетларын исәпкә алу | Яңа төзелешкә һәм хезмәтләр күрсәтүгә матди кыйммәтләр, җиһазлар, төзелеш материаллары өчен кайтартучылар белән төрле операцияләр башкаруга нигез булып торган документларны эшкәртү. Операцияләр журналында счетлар буенча әйәнешләрне һәм дебиторлар һәм кредиторлар белән исәп-хисапларны формалаштыру | операцияләр журналы, 1 позиция | 7,0 |
| 5.4. | Бюджетка түләүләр буенча исәп-хисапларны исәпкә алу | Салымнарның исәпләнгән һәм тотып калынган суммалары буенча бюджет белән исәп-хисаплар чагылдырыла торган счетлар буенча һәр айның әйләнеш ведомостьларын формалаштыру | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 3,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 5.5. | Йөкләмәләр буенча шәхси счетларга акча керүне исәпкә алу | Учреждениеләрнең шәхси счетларына акча керүләрне аналитик исәпкә алу | операцияләр журналы, 1 позиция | 7,0 |
| 6. Финанслау буенча ведомство эчендәге исәп-хисапларны исәпкә алу | | | | |
| 6.1. | Учреждение чыгымнары һәм башка чаралар бюджетыннан финанслау буенча ведомство эчендәге исәп-хисапларны исәпкә алу | Акчаны һәм исәп-хисапларны исәпкә алу карточкасында ведомство эчендәге факттагы исәп-хисапларны исәпкә алу. Учреждение чыгымнары һәм башка чаралар бюджетыннан ведомство эчендәге финанслауны исәпкә алу операцияләре чагылдырыла торган счетлар буенча әйләнеш ведомостьларын формалаштыру | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 6,0 |
| 6.2. | Башка бюджетлар акчасы исәбеннән финанслау буенча ведомство эчендәге исәп-хисапларны исәпкә алу | Башка бюджетлар исәбеннән ведомство эчендәге финанслауны исәпкә алу операцияләре чагылдырыла торган счетлар буенча һәр көннең әйләнеш ведомостьларын формалаштыру | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 3,5 |
| 6.3. | Капитал салулар бюджетыннан финанслау буенча ведомство эчендәге исәп-хисапларны исәпкә алу | Капитал салулар бюджетыннан ведомство эчендәге финанслауны исәпкә алу операцияләре чагылдырыла торган счетлар буенча һәр көннең әйләнеш ведомостьларын формалаштыру | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 6,0 |
| 7. Акча һәм кредит операцияләре исәп-хисапларын исәпкә алу | | | | |
| 7.1. | Башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр өчен кайтартучылар, подрядчылар һәм заказчылар белән исәп-хисапларны исәпкә алу | Башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр өчен кайтартучылар, подрядчылар, заказчылар белән исәп-хисап операцияләрен башкаруга нигез булып торган документларны эшкәртү. Операцияләр журналында башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр өчен кайтартучылар, подрядчылар һәм заказчылар белән исәп-хисапларны исәпкә алуны алып бару | операцияләр журналы, 1 позиция | 5,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 7.2. | Хисап бирергә тиешле затлар белән исәп-хисапларны исәпкә алу | Аванс хисапларын эшкәртү, касса ордерларыннан өземтә | операцияләр журналы, 1 позиция | 3,0 |
| 7.3. | Төрле дебиторлар һәм кредиторлар белән исәп-хисапларны исәпкә алу | Дебиторлар һәм кредиторлар белән исәп-хисап операцияләрен башкару өчен нигез булып хезмәт итә торган документларны эшкәртү. Операцияләр журналында исәпкә алуны алып бару | операцияләр журналы, 1 позиция | 6,0 |
| | | 8. Чыгымнарны исәпкә алу | | |
| 8.1. | Чыгымнарны исәпкә алу:<br>а) учреждениене тоту һәм башка чаралар бюджеты буенча;<br>б) башка бюджетлар акчасы исәбеннән;<br>в) капитал салулар бюджеты буенча | Хисап чорына һәм ел башыннан чыгымнар статьялары, чыгымнарны исәпкә алу объектлары һәм синтетик счет буенча һәр көн әйләнешләрен, тулаем чыга торган сальдо формалаштыру | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 3,5 |
| 8.2. | Башка чыгымнарны исәпкә алу | Хисап чорына һәм ел башыннан чыгымнар, чыгымнар төркемнәре, чыгымнарны бүлү тәртибендә исәптән төшерү буенча һәм синтетик исәпкә алу буенча һәр көн әйләнешләрен формалаштыру | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 3,5 |
| | | 9. Бюджеттан финанслауны исәпкә алу | | |
| 9.1. | Түбәндәгеләр бюджетыннан финанслауны исәпкә алу:<br>а) учреждение чыгымнары һәм башка чаралар; | Финанслар хәрәкәтен исәпкә алу буенча бухгалтерлык операцияләрен чагылдыру | операцияләр журналы, 1 позиция | 4,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | б) капитал салулар;<br>в) башка бюджетлар акчасы исәбеннән | | | |
| 9.2. | Учреждениенең башка акчасын, шул исәптән керем китерә торган эшчәнлектән кергән акчаны, гражданнар акчасын, чыгымнарны, грантларны һ.б. каплауны исәпкә алу | Учреждениене тотуга башка акчаны исәпкә алу буенча бухгалтерлык операцияләрен чагылдыру. Операцияләр журналында язуларны алып бару | операцияләр журналы, 1 позиция | 3,0 |
| 10. Продукция реализациияләүне исәпкә алу | | | | |
| 10.1. | Продукцияләр, эшләнмәләрне, башкарылган эшләрне реализацияләүне һәм башка керемнәрне исәпкә алу | Продукция тапшыру буенча тиешле документларны эшкәртү. Продукция реализацияләүне исәпкә алу буенча бухгалтерлык операцияләрен чагылдыру. Бухгалтерлык һәм склад исәбен чагыштырып тикшерү | операцияләр журналы, 1 позиция | 3,0 |
| 11. Керемнәрне исәпкә алу | | | | |
| 11.1. | Керемнәрне исәпкә алу | Хисап чорына һәм ел башыннан керемнәр буенча һәр көн әйләнешләрен формалаштыру | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 3,5 |
| 11.2. | Табышларны һәм зыяннарны исәпкә алу | Табышлар (зыяннар) суммаларының исәп-хисабы буенча квартал мәгълүматларын формалаштыру. Хисаплылык формаларын тутыруга мәгълүмат әзерләү | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 3,8 |
| 12. Тапшырылган һәм алынган акчаны исәпкә алу | | | | |
| 12.1. | Тапшырылган һәм алынган акчаны исәпкә алу | Тапшырылган һәм алынган акча хәрәкәте чагылдырыла торган счетлар буенча һәр ай әйләнешләрен формалаштыру. Операцияләр журналында акчаны исәпкә алуны алып бару | әйләнеш ведомосте, операцияләр журналы, 1 позиция | 5,6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | 13. Бюджет үтәлеше нәтиҗәләрен исәпкә алу | | |
| 13.1. | Бюджет үтәлеше нәтиҗәләрен исәпкә алу | Бюджет үтәлеше нәтиҗәләре чагылдырыла торган счетлар буенча һәр айның әйләнеш ведомостьларын формалаштыру | әйләнеш ведомосте, 1 позиция | 4,0 |
| 13.2. | Чыгымнарны санкцияләүне исәпкә алу, бюджет һәм акча йөкләмәләрен кабул итү | Һәр көннең әйләнеш ведомостьларын формалаштыру. Операцияләр журналында язуларны алып бару | әйләнеш ведомосте, операцияләр журналы, 1 позиция | 4,0 |
| | | 14. Баланстан тыш счетларны исәпкә алу | | |
| 14.1. | Баланстан тыш счетларны исәпкә алу | а) файдалануга алынган мөлкәтне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | б) саклауга кабул ителгән матди кыйммәтләрне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | в) катгый хисаплылык бланкларын исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | г) шикле бурычны исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | д) үзәктән тәэмин итү буенча түләнгән матди кыйммәтләрне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | е) укучыларның һәм студентларның кире кайтарылмаган матди кыйммәтләр өчен бурычын исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | ж) матди кыйммәтләрне (бүләкләрне, призларны, кубокларны һәм кыйммәтле бүләкләрне, сувенирларны) исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | з) юлламаларны исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | и) транспорт чараларының таушалган запас частьләре урынына бирелгән запас частьләрен исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | к) йөкләмәләр үтәлешен тәэмин итүне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | л) дәүләт гарантияләрен һәм муниципаль гарантияләрне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | м) заказчылар белән шартнамәләр буенча фәнни тикшеренү эшләрен башкару өчен махсус җиһазны исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | н) эксперименталь җайланмаларны исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | о) үткән елларның ачыкланмаган керемнәрен исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | п) кредиторлар тарафыннан таләп ителмәгән бурычны исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | р) эксплуатацияләнә торган төп чараларны исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | с) үзәктән тәэмин итү буенча алынган матди кыйммәтләрне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | т) файдалану өчен вакытлы басмаларны исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | у) ышанычлы идарәгә тапшырылган, финанс булмаган активларны исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | ф) түләүле файдалануга (арендага) тапшырылган мөлкәтне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | х) түләүсез файдалануга тапшырылган мөлкәтне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | ц) хезмәткәрләргә (эшчеләргә) шәхси файдалануга бирелгән матди кыйммәтләрне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | ч) торак сатып алуга бирелгән субсидияләрне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | ш) өченче зат аша акчалата йөкләмәләр үтәлеше буенча исәп-хисапларны исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | щ) номиналь кыйммәте буенча акцияләрне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | ъ) репо шартнамәләре буенча кыйммәтле кәгазьләрне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | ы) матди булмаган активларга махсус булмаган хокукларны исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | ь) матди булмаган активлар составындагы матди мәгълүмат саклагычларны исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| | | э) хезмәткәрләрдән вакытлыча файдалануга алынган мөлкәтне исәпкә алу | ведомость, 1 позиция | 14,0 |
| 14.2. | Инвентаризация үткәргәндә балансстан тыш счетларны исәпкә алу | Балансстан тыш счетларда мөлкәт булу турында мәгълүмат өземтәсе | инвентаризация исемлеге яки исәпкә алуның инвентарь карточкасы, 1 позиция | 2,4 |
| 15. Кыйммәтле документлар бирү; һәр көннең касса хисабы төзү | | | | |
| 15.1. | Банкта хезмәткәр (матди җаваплы зат) картасына акча алу | Хезмәткәр (матди җаваплы зат) картасына акча алу | 1 тапкыр банкта акча алу | 22,0 |
| 15.2. | Физик затлардан кассага акча (һәр көн) керү (әзер продукция сату, хезмәт күрсәтүләр) | Контроль-касса машинасы аша кассага акча керү (керем касса ордерын рәсмиләштерү) | керем касса ордеры, 1 позиция | 1,4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 15.3. | Кассадан акча бирү | Түләү ведомостенда алучының имзасын куйдыру, хисап һәм акча бирү | 1 тапкыр кассадан акча бирү | 1,4 |
| 15.4. | Акчаны банкка хезмәткәр (матди җаваплы зат) картасына тапшыру, кәгазь акчаны банкка учреждениенең шәхси счетына тапшыру | Акчаны банкка хезмәткәр (матди җаваплы зат) картасына тапшыру, кәгазь акчаны банкка учреждениенең шәхси счетына тапшыру | 1 тапкыр банкка акча тапшыру | 22,0 |
| 15.5. | Кыйммәтле документлар бирү | Касса ордерына «Фонд» язуын рәсмиләштереп һәм касса кенәгәсенә «Фонд» язуын рәсмиләштереп, һәр касса ордеры буенча язу. Кыйммәтле документлар бирү | 1 тапкыр кыйммәтле документларны бирү | 8,0 |
| 15.6. | Һәр көннең касса хисабын төзү | Барлык кирәкле мәгълүматны хисап формасына кертү | 1 касса хисабы | 24,0 |
| | | 16. Хисаплылык төзү | | |
| 16.1. | Бухгалтерлык хисаплылыгы | Тиешле форма буенча хисап төзү | 1 тапкыр үткәрү, финанс елын тәмамлау буенча регламент операцияләреннән һәм хисап чоры арасындагы операцияләрдән тыш | 12,0 |
| 16.2. | Ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык хисаплылыгы | Россия Федерациясе Финанс министрлыгының норматив документларында билгеләнгән ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең билгеле бер вакыт саен бирелә торган хисаплылыгын тикшерү | 1 хисап | 15,0 |

4.3. Хезмәткәрләр (бухгалтерлар) саны нормативы «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт информацион системасында узган өч елда теркәлгән операцияләр санын исәпкә алып, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе эшчәнлегенә тулаем анализ ясау нигезендә билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин